КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 октябрь г.Казань № 857

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре өчен товарларның аерым төрләрен (хезмәтләрнең аерым төрләрен) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләүне оештыру турында» 2015 ел, 30 март, 197 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре өчен товарларның аерым төрләрен (хезмәтләрнең аерым төрләрен) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе арасындагы килешү (алга таба – Килешү) формасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре өчен товарларның аерым төрләрен (хезмәтләрнең аерым төрләрен) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләүне оештыру турында» 2015 ел, 30 март, 197 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 11 декабрь, 1119 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре өчен товарларның аерым төрләрен (хезмәтләрнең аерым төрләрен) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт

учреждениесе арасындагы килешү (алга таба – Килешү) формасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

2.1.8 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

2.1.9 пунктчада «документларның» сүзен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында белдерүнең» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта:

4.1.4 пунктчада:

беренче абзацта «документлар, Техник бирем, дәүләт контракты проекты» сүзләрен «Техник бирем, контракт проекты» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «һәм (яки) документларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.5. Сатып алуны гамәлгә ашыру турында белдерүгә үзгәреш кертергә кирәк булган очракта яки кайтартучыны (башкаручыны) билгеләүне гамәлдән чыгарган очракта, Вәкаләтле орган кайтартучыны (башкаручыны) билгеләүне гамәлдән чыгару турында йә сатып алуны гамәлгә ашыру турында белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында карар кабул итү өчен законнарда билгеләнгән срок чыкканга кадәр ике көн кала хәбәр итә;»;

4.2 пунктта:

4.2.1 пунктчада «Детальләштерелгән исемлек нигезендә товарлар (хезмәт күрсәтүләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.2.5 пунктчада «һәм документларны раслый» сүзләрен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында белдерү» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.6. Сатып алуны гамәлгә ашыру турындагы белдерүне әлеге пунктның 4.2.5 пунктчасы нигезендә аны әзерләгән көннән алып бер эш көне эчендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра.

Кирәк булганда сатып алуны гамәлгә ашыру турында белдерүгә үзгәрешләр кертә;»;

4.2.7 пунктчада «тапшырылган документлар» сүзләрен «тапшырылган сатып алуны гамәлгә ашыру турында белдерү» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.10 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Вәкаләтле органның кайтартучыны (башкаручыны) билгеләү буенча гамәлләре бердәм мәгълүмат системасында конкурс, аукцион уздыру буенча йомгаклау беркетмәсе урнаштырылган көннән тәмамлана.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин